РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Пер.Советский , д.44а, с.Алькеево, Азнакаевский район, 423309

Пер.Совет ур. 44а нче йорт, Әлкәй авылы, Азнакай районы, 423309

Тел./факс(885592)-37-4-23; E-mail: Alk.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» сентябрь 2018 ел № 16

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

“2019 елда үзара салым кертүгә Әлкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру өчен;
2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру өчен;
3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен;
4) һәйкәлне төзекләндерү өчен;
5) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру өчен

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:
Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стенды: ТР, Азнакай районы, Әлкәй авылы, Совет бистәсе, 4а йорт, Әлкәй авылы китапханәсе, 34 йорт.
- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru.
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

Рәис С.З. Зиннурова